**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИКЛӘНАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«20» декабря 2024 ел №18

«2020 елда Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бикләнавыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бикләнавыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31 мартындагы 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бикләнавыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2020 елда Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31 мартындагы 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. исемендә «2020 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2 пунктны төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бикләнавыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31 мартындагы 5 номерлы карары белән расланган 2020 елда Тукай муниципаль районы Бикләнавыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе»;

2.2. 3 пунктта «, муниципаль программаларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.3. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү максатында, Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Башкарма комитеты:

а) муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеген төзү тәртибен билгели;

б) муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының норматив, максатчан һәм фискаль характеристикалары турында мәгълүмат формалаштыру кагыйдәләрен

билгели;

в) муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары кураторлары тарафыннан башкарыла торган салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү йомгакларын гомумиләштерү тәртибен билгели.»;

2.4. 7 пунктта «хисап финанс елы һәм хисап чорына кадәрге ел өчен муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының фискаль характеристикалары турында мәгълүмат бирә» сүзләрен «хисап финанс елы өчен муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының фискаль характеристикалары турында, шулай ук хисап финанс елына кадәрге 6 ел өчен муниципаль берәмлекнең стимуллаштыручы салым чыгымнары турында мәгълүмат бирә.» сүзләренә алыштырырга;

2.5. 12 пунктта:

- икенче абзацта «муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

- өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бирелгән ташламаларга түләүчеләрнең 5 еллык чор өчен ташламалар хокукыннан файдаланган түләүчеләр саны һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр саны яки түләүчеләрнең гомуми саны нисбәте белән характерлана торган ихтыяҗы.»;

2.6. 13 пунктта «яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга керми торган социаль-икътисадый сәясәте максатларына» сүзләрен « һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга керми торган социаль-икътисадый сәясәте максатларына» сүзләренә алыштырырга;

2.7. 16 пунктның беренче абзацында «муниципаль берәмлек муниципаль программалары салым чыгымнарының 1 сумына» сүзләрен «муниципаль берәмлек салым чыгымнарының 1 сумына» сүзләренә алыштырырга;

2.8. 17 пунктта:

- беренче абзацта «1 октябрьгә кадәр» сүзләрен «ел саен, 1 октябрьгә кадәр» сүзләренә алыштырырга;

- өченче абзацта «социаль-икътисадый сәясәт юнәлешләренә (максатларына)» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларына» сүзләренә алыштырырга;

2.9. кушымтада:

- 14 юлда «дәүләт программаларына» сүзләрне «муниципаль программаларга» сүзләренә алыштырырга;

- түбәндәге эчтәлектәге 19 юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| 19. | Салым түләүчеләрнең (берәмлекләрнең) гомуми саны |

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе М.Ш.Сәхбеев